**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**НИЖНЕКАМЕНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КӘМИНКӘ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Улица Центральнаяя, дом 51,
село Нижняя Каменка, 423114

Үзәк урамы, 51 йорт,
Түбән Кәминкә авылы, 423114

тел./факс 843962-35-21 email: Nkam.Cmn2@tatar.ru

**15.11.2018** **№ 106**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Түбән Кәминкә авыл җирлегенең**
**2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджеты турында**

Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге башлыгы Р. Р. Халиковның докладын тыңлап һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына бюджеты проектын карап, карар кабул итте:

"Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджеты турында»карар проектын беренче укылышта хупларга һәм халык алдында тыңлауларга чыгарырга.

**Статья 1.**

1. Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджетының 2019 елга төп характеристикаларын расларга:

1) Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджетының гомуми керем күләме **5713,07** сум;

2) Чирмешән муниципаль районының Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме **5713,07** мең сум.

3) Чирмешән муниципаль районының Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджеты кытлыгы күләме **0,0** мең сум.

2.Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын раслау турында:

1)Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджетының 2020 елга фаразланыла торган керемнәренең гомуми күләме **5631,6** мең сум һәм 2021 елга **5649,20** мең сум:

2) Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең гомуми чыгымнары күләме:

2020 елга **5631,60** сум , шартлы рәвештә расланган чыгымнар **140,79** мең сум

2021 елга **5649,20** мең сум , шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар **282,46** мең сум.

3) Чирмешән муниципаль районының 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**Статья 2**

1. 2019 елның 1 гыйнварына Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген **0,0** мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча **0,0** мең сум күләмендә.

2. 2020 елның 1 гыйнварына Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча Эчке муниципаль бурычның иң югары чиген **0,0** мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча **0,0** мең сум күләмендә.

3. 2021 елның 1 гыйнварына Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча Эчке муниципаль бурычның иң югары чиген **0,0** мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча **0,0** мең сум күләмендә.

**Статья 3**

Чирмешән муниципаль районының Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджетында әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.

**Статья 4**

1. Әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә җирле үзидарә органнары бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген расларга.

2. Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

**Статья 5**

1. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

2. 2019 елга Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын 6 нчы кушымтасы нигезендә расларга

3. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджет чыгымнарының максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекчәләре, буенча бюджет ассигнованиеләрен әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә бүлүне расларга.

4. Бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2019 елга **15 мең сум** 2020 елга **16 мең сум** һәм 2021 елга **17 мең сум** күләмендә расларга .

**Статья 6**

Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджетында Чирмешән муниципаль районы бюджетыннан алына торган 2019 елда **2791,57 сум**, 2020 елда **2663,59 сум** һәм 2021 елда **2646,48 сум** күләмендә бюджетара трансфертларны әлеге карарның 8 кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

**Статья 7**

Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге башкарма комитеты 2018 елда муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм башка оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

**Статья 8**

1.Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджет учреждениеләре тарафыннан эшмәкәрлек һәм башка керем китерә торган эшчәнлектән алынган акчалар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнарында ачылган шәхси счетларда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән генераль рөхсәтләр нигезендә исәпкә алына.

2.Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджет учрежденияләре белән төзелгән килешүләр эшмәкәрлек һәм башка керем китерә торган эшчәнлектән кергән акчалар хисабына гамәлгә ашырыла, расланган керемнәр һәм чыгымнар сметасы чикләрендә башкарыла дип билгеләргә.

3. 2019 елда Чирмешән муниципаль районының Түбән Кәминкә авыл җирлеге милкендә булган һәм бюджет мәдәният, сәнгать, сәламәтлек саклау, мәгариф учреждениеләренә, шулай ук архив учреждениеләренә оператив идарәгә тапшырылган мөлкәтне арендага бирүдән кергән керемнәр Чирмешән муниципаль районы бюджеты керемнәре составына кертелә һәм әлеге карар нигезендә бюджет йөкләмәләрен үтәү өчен файдаланыла дип билгеләргә.

**Статья 9**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары, төзелгән килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

**Статья 10**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджеты акчаларының Чирмешән муниципаль районы исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар шартлары нигезендә 2018 елда түләнергә тиешле товарлар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә калдыклары (статья 2007 елның 2 августындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә), 2019 елда Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**Статья 11**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджетын үтәгәндә әлеге карар белән расланган керемнәрнең гомуми күләменнән тыш фактта алынган керемнәр, әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә, муниципаль бурычны түләүгә, суд актларын үтәүгә, шулай ук аларны үтәү өчен каралган бюджет ассигнованиеләре җитмәгән очракта,Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 217 статьясындагы 3 пункты нигезендә норматив йөкләмәләрне үтәүгә билгеләнгән тәртиптә җибәрелә .

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджетын үтәгәндә фактта алынган субсидияләр, субвенцияләр һәм бюджетара трансфертлар, әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертмичә, субсидияләр, субвенцияләр һәм бюджетара трансфертлар бирү максатларында чыгымнарны арттыруга юнәлдерелә.

**Статья 12**

Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Статья 13**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына бюджеты турында» әлеге карарны мәгълүмат стендында һәм Чирмешән муниципаль районының Интернет челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга тиеш.

2. 2018 елның 6 декабрендә 13.00 сәгатьтә Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджеты проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә. Үткәрү урыны итеп Түбән Кәминкә авылы, Үзәк урамы, 51 нче йорт адресы буенча урнашкан Түбән Кәминкә авыл мәдәният йортын билгеләргә.

3. Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советының икътисад сәясәте һәм бюджет буенча Даими комиссиясе халык алдында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм сессиягә кертергә тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кәминкә авыл җирлеге советы рәисе,
җирле үзидарә башлыгы Р.Р. Халиков